**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"04" ноябрь 2019 ел. № 3-2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законнын 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Иске Өҗем торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем авылы территориясендә 2020 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

а)Территорияне төзекләндерү:

- Таш-Чишмә авылында күлне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, Транспорт хезмәтләре өчен түләү һәм эш өчен түләү);
- Таш-Чишмә, Иске Өҗем авыллары территорияләрен төзекләндерү һәм чистарту (агач кисү, транспорт хезмәтләре күрсәтү);

б)Балалар мәйданчыгын төзекләндерү һәм җиһазлар сатып алу. Иске Өҗем авылы;

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем авылында яшәүче халык җыенынын әлеге карарын Өҗем авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Өҗем авыл җирлеге башлыгы Вәлиев А.Т.